**ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

от 13 декабря 2013 года г. Казань № 10-59/кс

***Эчәргә яраклы суга һәм ташландык суларны агызу тарифлары***

“Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу турында” 7 декабрь, 2011 ел, № 416-ФЗ Федераль законга, “Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендә тарифларны дәүләти җайга салу турында” 13 май, 2013 ел, №406 Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына, “Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендә гамәлдәге тарфиларның максималь мөмкин булган үзгәртү чик индексларын, 2014 елда уртача Россия Федерациясе буенча билгеләү турында” 21 октябрь, 2013 ел, Тарифлар буенча Федераль хезмәтенең боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 15 июнь, 2010 ел, № 468 карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә туры китереп, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты **карар бирә**:

1. Әлеге карарның кушымтасына таянып, салкын су белән тәэмин итүче һәм ташландык суларны агызган оешмалар өчен, календарь бүленеше нигезендә, эчәргә яраклы һәм ташландык суларны агызу тарифларын билгеләргә.

2. Бу карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2014 елның 1 гыйнварыннан 2014 елның 31 декабренә кадәр үз көчендә була.

3. Бу карарга кушымтада күрсәтелгән салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык суларны агызуны хәл итүче оешмаларга Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 17 гыйнвар, 2013 ел, № 6 карары белән расланган мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә чираттагы җайга салу чорына тарифны билгеләү турында карар кабул ителгәннән соң 30 көннән дә соңга калмыйча халыкка җиткерелергә тиешле мәгълүматны ачарга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы тарифлар
буенча Дәүләт комитеты Рәисе М.Р. Зарипов

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
Дәүләт комитеты карарына кушымта
13 декабря 2013 ел № 10-59/кс

Салкын су белән тәэмин итүче һәм ташландык суларны агызган оешмалар өчен,
календарь бүленеше нигезендә,
эчәргә яраклы һәм ташландык суларны агызу тарифлары

| № п/п | Наименование муниципаль берәмлек, оешма, салкын су белән тәэмин итүче һәм ташландык суларны агызган оешмалар | Техник су тарифлары (бер ставкалы), сум./куб.м | | Эчәргә яраклы суга тариф (бер ставкалы), сум./куб.м | | Салкын суны траспортлау тарифы (бер ставкалы), сум./куб.м | | Ташландык суларны агызу (бер ставкалы), сум./куб.м | | Ташландык суларны транспортлау тарифлары (бер ставкалы), сум./куб.м | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 01 гыйнвар 2014 ел - 30 июнь 2014 ел | 01 июль 2014 ел - 31 декабрь 2014 ел | 01 гыйнвар 2014 ел - 30 июнь 2014 ел | 01 июль 2014 ел - 31 декабрь 2014 ел | 01 гыйнвар 2014 ел - 30 июнь 2014 ел | 01 июль 2014 ел - 31 декабрь 2014 ел | 01 январь 2014 ел. - 30 июнь 2014 ел | 01 июль 2014 ел - 31 декабрь 2014 ел | 01 гыйнвар 2014 ел - 30 июнь 2014 ел | 01 июль 2014 ел - 31 декабрь 2014 ел |
| | Аксубай муниципаль районы | | | | | | | | | | |
| 1 | ҖЧҖ «Торак-коммуналь хуҗалыгы күп өлкәле җитештерү предприятиясе»* | | | 16,33 | 16,33 | | | 19,69 | 19,69 | | |
| | Бөгелмә муниципаль районы | | | | | | | | | | |
| 2 | ҖЧҖ «Бөгелмә-Водоканал» | | | | | | | | | | |
| | Торак секторы кулланучылары (тарфиларда ӨБС исәпкә алынган) | | | 27,51 | 29,54 | | | 13,02 | 14,31 | | |
| | Башка кулланучылар (ӨБС исәпкә алынмаган) | | | 23,31 | 25,03 | | | 11,03 | 12,13 | | |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Лаеш муниципаль районы | | | | | | | | | | |
| 3 | ЖЧЖ «Лаеш Коммуналь Хезмәте»* | | | 27,03 | 28,39 | | | 34,05 | 37,67 | | |
| 4 | ЖЧЖ «КомЭкоКомплекс»* | | | 21,98 | 24,46 | | | 35,20 | 38,14 | | |
| | Менделеевск муниципаль районы | | | | | | | | | | |
| 5 | ЖЧЖ «Комфорт»* | | | 20,62 | 22,18 | | | | | | |
| 5.1 | Ижау авыл җирлеге авыл хуҗалыгы | | | | | | | | | 14,57 | 14,57 |
| 5.2 | Мунайкино авыл җирлеге кулланучылары | | | 29,11 | 31,73 | | | 15,66 | 15,66 | | |
| 5.3 | Татар-Чаллы авыл җирлеге кулланучылары | | | | | | | 16,34 | 16,34 | | |
| | Түбән Кама муниципаль районы | | | | | | | | | | |
| 6 | ЖЧЖ «Жилкомсервис»* | | | 26,85 | 28,49 | | | 32,96 | 34,73 | | |
| | Казан шәһәре | | | | | | | | | | |
| 7 | Җылылык һәм су белән тәэмин итү Горький дирекциясе Казан территориаль участогы - Җылылык һәм су белән тәэмин итү Үзәк дирекциясе - ААҖ «РЖД» филиалы (ӨБС исәпкә алынмаган) | 26,83 | 32,87 | | | 7,64 | 7,64 | | | 6,26 | 6,26 |

<*> оешма гадиләштерелгән салым алу системасын куллана
<**> Россия Федерациясе Салымнар кодексының 168 статьяның 6 пунктын тормышка ашыру максатын күздә тотып аерылып бирелгән

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
Дәүләт комитеты,
Тарифлар буенча карарларны кабул итү,
оештуры һәм җайга салу бүлеге